**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында үзара салым акчасын кертү һәм аннан файдалану буенча халык җыены КАРАРЫ**

2024 елның 27 нче ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында халык җыены КАРАР бирде:

1. Үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан,балачактан инвалидлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, ялгыз өлкән пенсионерлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
-Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Шеншеңәр авылындагы һәйкәлне төзекләндерү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Комсомольская урамы буенча асфальт җәю).

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Х.Салихҗанов